**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.6[1] статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2020 елның 6 апрелендәге ПУ-224 номерлы Указы нигезендә расланган Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.6[1] статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары исемлегенең 2 пунктына, аңа түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«территориаль идарәләр башлыклары;

территориаль идарәләр башлыклары урынбасарлары;

территориаль бүлекләр башлыклары.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 03 декабрь
№ ПУ-802